СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

31.05.2019 Алабуга шәһәре № 365

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Яковлево авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре «нә үзгәрешләр кертү проектын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексы, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» ТР Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Яковлево авыл җирлеге Советының 2019 елның 27 маенда чыккан 163 санлы «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Яковлево авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре»нә үзгәрешләр кертү проектын килештерү турында» гы Карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Яковлево авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын раслау турындагы проектны түбәндәге составта расларга:

1.1. Татарстан Республикасы, Яковлево авыл җирлеге адресы буенча урнашкан СУ (авыл хуҗалыгы җирләре зонасы) территориаль зонаны кадастр номеры 16:18:070701:440, мәйданы 10000 кв.м. булган җир кишәрлеген СХ1 зонасына (агросәнәгать комплексы объектларын һәм агросәнәгать комплексына хезмәт күрсәтү объектларын урнаштыру зонасы) үзгәртү.

1.2. Татарстан Республикасы, Яковлево авыл җирлеге адресы буенча урнашкан СУ (авыл хуҗалыгы җирләре зонасы) территориаль зонаны кадастр номеры 16:18:070701:434, мәйданы 80000 кв.м. булган җир кишәрлеген СХ1 зонасына (агросәнәгать комплексы объектларын һәм агросәнәгать комплексына хезмәт күрсәтү объектларын урнаштыру зонасы) үзгәртү.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны шәһәр төзелеше һәм инфраструктура үсеше мәсьәләләре буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

Рәис Г.Е. Емельянов